**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АККҮЗ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

423744, Аккүз авылы,
Үзәк ур.,1 нче йорт. Тел.3-44-42

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АККУЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423744, село Аккузово,
ул. Центральная,дом 1, Тел. 3-44-42

ПОСТАНОВЛЕНИЕ №3 КАРАР
15.01.2022

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлегендә җирләү эше мәсьәләләре буенча попечительләр советы турындагы нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл бирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлегендә җирләү эше мәсьәләләре буенча Попечительләр советы турындагы нигезләмәне (кушымта) расларга.
2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Аккүз авыл җирлегендә җирләү эше мәсьәләләре буенча Попечительләр советы составын расларга (кушымта).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://aktanysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Аккүз авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Имамова Г.И.